КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь г.Казань № 1444

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 октябрь, 1007 нче карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 октябрь, 1007 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 август, 803 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары,

аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

9 пунктның өченче абзацында «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин